# КЫТАЙ ҖЫЕЛМА КОМАНДАСЫ ХАТЫН-КЫЗЛАР АРАСЫНДА 4X100 ДИСТАНЦИЯГӘ КОМПЛЕКСЛЫ ЙӨЗҮ ЭСТАФЕТАСЫНДА АЛТЫН МЕДАЛЬ АЛДЫ

09.08.2015, 19:36

СПОРТ

**8 нче финал йөзеше ахырына якынлашты, аның белән беррәттән Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты да тәгәлләнде. 4x100 дистанциягә комплекслы йөзү эстафетасында дөньяның иң әйбәт спортчы кызлары ярышты.**

Алтын медаль иясләре булып Кытай милли җыелма командасы кызлары билгеләнде, 3:54.41 секундлы күрсәткеч белән алар финишка беренче булып килделәр. Алар артыннан финиш сызыгын швед йөзүчеләре кисте, аларның күрсәткече - 3:55.24 секунд. Призерлар өчлеген австралиялеләр япты - алар дистанцияне 3:55.56 секунд күрсәткече белән үттеләр. Сүз уңаеннан, пьедесталдагы урыннар өчен ике команда көрәшә алмады - Бөекбритания һәм Япония җыелма командалары ярыштан чыгарылдылар.

ДЧ-2015. Йөзү.

1. Кытай - 3:54.41

2. Швеция - 3:55.24

3. Австралия - 3:55.56

9 август. Казан. "Казан-Арена".

Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты Оештыру комитеты матбугат хезмәте

ЯҢАЛЫКЛАР ТАСМАСЫН АЧАРГА